**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2022 елның 28 декабре** **3402 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы , Лаеш муниципаль районы, Пелевка авыл җирлеге, Пелево авылы, Йолдыз ур., 20а адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:030103:91 булган җир кишәрлеге территориясен межанлау проектын әзерләү турында.**

Территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын билгеләү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә капиталь төзелеш объектларын планлаштырылган урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы , Лаеш муниципаль районы, Пелевка авыл җирлеге, Пелево авылы, Йолдыз ур., 20а адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:030103:91 булган җир кишәрлеге территориясен межанлау проектын әзерләүгә керешергә.

2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 статьясы нигезендә билгеләргә.

3. 2023 елның 1 июненә кадәр ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын билгеләргә.

4. Әлеге карар бастырылганнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне межанлау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**